**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Первомайская ул., д.39, г. Лаишево, 422610
Тел: 8 (84378) 2-51-51
Факс: 8 (84378) 2-55-55
e-mail: Sovet.Laishevo@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

Беренче май ур., 39 нчы йорт, Лаеш ш., 422610
Тел: 8 (84378) 2-51-51
Факс: 8 (84378) 2-55-55
e-mail: Sovet.Laishevo@tatar.ru

---

**2025 елның 13 нче ноябрь** **номер 19-РС**

# КАРАР

## «Лаеш муниципаль районында хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе составын раслау турында» Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2021 елның 29 11 декабрендәге 105-РС номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Комиссия эшчәнлеген камилләштерү максатларында Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы **КАРАР ЧЫГАРДЫ**:

1. «Лаеш муниципаль районы Советының «Лаеш муниципаль районында хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе составын раслау турында» Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2021 елның 29 июнендәге 105-РС номерлы карары белән расланган мәнфәгатьләр конфликтын хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм җайга салу комиссиясе составына (2024 елның 11 июнендәге 48-РС номерлы соңгы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) комиссия составыннан Р.Т. Гарифуллинны, Р.В. Мышеваны чыгарырга;

2) комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Нурмөхәммәтов Азат Әнәс улын - Лаеш муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе, комиссия әгъзасы;

Абутдинова Эльмира Ирфан кызын - Лаеш муниципаль районы Иҗтимагый советы рәисе, комиссия әгъзасын (килешү буенча);

3) комиссия әгъзалары вазыйфаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Сатдинова Ленара Марат кызы - Лаеш муниципаль районының Чирпы авыл җирлеге башлыгы (килешү буенча);

Кузнецова Мария Григорьевна - «Лаеш техник-икътисадый техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директоры (килешү буенча)».

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru.

веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

**Муниципаль район Советы**
**рәисе-башлык вазифаларын башкаручы Т.П. Борһанова**